# Фәрештәләргә иман китерү

## الإيمان بالملائكة

اللغة التترية

Шәйх Хәйсәм ибн Мөхәммәд Сәрхән

ALSARHAAN.COM

الملائكة خلق من عباد الله ، خلقهم الله عز وجل من نور.

**Фәрештәләр – ул Аллаһның колларыннан булган мәхлуклар һәм алар нурдан яратылган.**

وأوجدهم لعبادته وطاعته.

**Аллаһ аларны Үзенә гыйбадәт кылсыннар һәм буйсынсыннар өчен барлыкка китерде.**

فبحمده يسبحون ولأوامره مطيعون.

**Һәм Аның рәхмәте белән алар гел Аллаһны данлыклыйлар һәм Аның әмерләренә гел буйсынып торалар.**

- قال الله تعالى: لا يعصون الله ما أمرهم ويفعلون ما يؤمرون

**Аллаһ әйтте: «Алар Аллаһның әмерләренә карышмыйлар һәм барлык әмер ителгән нәрсәләрне үтиләр».**

وهم خلق كثير لا يعلمهم إلا الله

**Аларның саны бик күп һәм күпме икәннәрен Аллаһтан башка беркем дә белми.**

والإيمان بالملائكة أصل من أصول الاعتقاد لا يتم الإيمان الا به.

**Фәрештәләргә иман китерү – иман нигезләренең берсе, аннан башка иман камил булмый.**

وهو يتضمن أربعة أمور:

**Фәрештәләргә иман китерү дүрт нәрсәдән тора:**

هي الاقرار الجازم بوجودهم وأنهم خلق من خلق الله مسخرون.

1. Алар бар икәненә һәм алар Аллаһның буйсынучы мәхлукларыннан булуына ныклап ышану.

- الإيمان باسم من ثبت اسمه منهم كجبريل وميكائيل واسرافيل وغيرهم عليهم السلام.

2. Җәбрәил, Микәил, Исрафил кебек һ.б. Аллаһ хәбәр иткән фәрештәләрнең исемнәренә ышану (аларга Аллаһның сәламе булсын).

- الإيمان بأوصاف من ثبت وصفه منهم كما جاء في وصف جبريل عليه السلام بأن له ست مئة جناح قد سد بهم الأفق.

3. Җәбрәилнең (аңа Аллаһның сәламе булсын) офыкларны капларлык алты йөз канаты бар дигән тасвирламага ышанган кебек фәрештәләр турында хәбәр ителгән сыйфатларга ышану.

الإيمان بأعمال من ثبت عمله منهم فجبريل عليه السلام موكل بالوحي، وملك الموت موكل بقبض الارواح، واسرافيل موكل بالنفخ في الصور، وميكائيل موكل بالمطر،
ومنهم الموكل بحفظ العبد في حله وترحاله وفي كل أحواله وهم المعقبات الذين قال الله في شأنهم:
له معقبات من بين يديه ومن خلفه يحفظونه من أمر الله

4. Аларның һәрберсенә берәр гамәл йөкләнгәненә ышану. Мәсәлән: Җәбраил фәрештә вәхи өчен җаваплы, үлем фәрештәсе җаннарны алуга җаваплы, Исрафил - быргыга өрүче, ә Микэил яңгыр өчен җаваплы. Шулай ук фәрештәләрдән аерылмас рәвештә гел колларны саклап торучылары бар. Һәм алар шулай ук күзәтүчеләр. Аллаһ Раббыбыз алар турында әйтте: «Аның алдында да, артында да күзәтеп торучылары бар һәм алар аны Аллаһның әмере буенча саклыйлар».

ومن الملائكة حملة العرش ومنهم زوار البيت المعمور.

**Шулай ук фәрештәләрдән Аллаһның гәрешен тотучылар һәм күктәге "Бәйтүл Мәгмур" дип исемләнгән өйгә кереп намаз укучы фәрештәләр бар.**

قال النبي صلى الله عليه وسلم رُفِعَ لي البيت المعمور فسألت جبريل فقال :هذا البيت المعمور يصلي فيه كل يوم سبعون ألف ملك، اذا خرجوا لم يعودوا إليه آخر ما عليهم.

**Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Мин күктәге "Бәйтүл Мәгмур" дип исемләнгән өйгә күтәрелдем, һәм Җәбраилдән: "Нәрсә бу?",- дип сорадым. Ул: "Бу – "Бәйтүл мәгмүр" һәм монда көн саен җитмеш мең фәрештә кереп намаз укып чыга, һәм бер кергән фәрештә башка беркайчан да кире әйләнеп кайтмый",- дип җавап кайтарды".**

ومنهم الملائكة الكرام الكاتبون وهم الموكلون بحفظ عمل العبد وكتابته خير أو شر.

**Шулай ук фәрештәләрдән язып баручы хөрмәтле фәрештәләр бар. Алар кешеләрнең яхшы һәм яман гамәлләрен язып баруга җаваплы.**

فاحرص على سلامة إيمانك بالملائكة من كل شائبة.
Шулай итеп синдә фәрештәләргә хата-кимчелекләрдән пакь булган гадел, ныклы ышану булсын.

ومن عادى أحدًا من ملائكة الله فقد صار عدوا لله.
Кем дә кем Аллаһның берәр фәрештәсенә генә булса да дошманлык хисе кичерсә, үзе дә Аллаһның дошманына әверелер.

قال تعالى: قل من كان عدوًا لله وملائكته ورسله وجبريل وميكال فإن الله عدوٌّ للكافرين.

Аллаһ әйтте:
«Әйт: кем дә кем Аллаһ белән, Аның фәрештәләре, илчеләре, Җәбраил һәм Микәил белән дошманлашса (шул чакта ул кәфергә әйләнә), ә чынлыкта Аллаһ кәферләрнең дошманы».